**«Килешенде»**
Арча районы Кәче төп гомуми
белем мәктәбе тәрбия эшләре буенча директор урынбасары
_____________/ Әхмәтҗанова Э.Г./
" 31 " август 2023 ел

**«Расланды»**
Арча районы Кәче төп гомуми белем мәктәбе директоры
_____________/Ахметова Г.З./
Приказ № 84
" 31 " август 2023 ел

# *"Дуслык"*

## Балалар оешмасының 2023- 2024 нче уку елы өчен еллык эш планы

Педагог-оештыручы: Нигъмәтҗанова А.Р.

Педагогик совет
утырышында каралды
Беркетмә №1
" 31 " август 2023 ел

Балалык еллары һәр кеше тормышында шәхес буларак үсеш чоры. Бала чакта һәркем файдалы эштә катнашырга, яшьтәшләре белән тиешле дәрәҗәдә аралашырга, коллективта үзен күрсәтергә, танылырга омтыла.

Тәрбия эше бервакытта да җиңел бирелми. Бугенге көндә бу аеруча актуаль мәсьәлә. Хәзер купчелек балаларны телевидение һәм урам тәрбияли. Без, педагоглар балаларны тәрбияләүгә барлык көчебезне куярга тиеш. Кызлар һәм малайларның төрле оешмаларга берләшеп, файдалы эшчәнлек алып барулары табигый хәл. Һәр бала узенчә сәләтле, талантлы. Баланың бирелгән сәләте тулысынча ачылсын өчен акыллы оештыручы кирәк.

Балалар оешмалары - иҗтимагый тормыш мәктәбе ул. Анда катнашу һәм вакытны файдалы, кызыклы итеп үткәрергә, шәхес буларак танылырга ярдәм итә. Үз оешмаларында балалар демократиягә һәм хәбәрдарлыкка, башкаларны инандырырга, кирәкле фикерне тыңлый белергә, активлыкны курсәтергә, уңай традицияләрне сакларга, яңаларын барлыкка китерергә өйрәнәләр.

Әлеге программада  Арча районы Кәче төп гомуми белем бирү мәктәбенең балалар оешмасының эшчәнлеге чагыла. Программаның төп үзенчәлеге: балаларның яшь узенчәлекләрен, мөмкинлекләрен исәпкә алу. Балаларның кызыклы, файдалы тормыш белән яшәвенә, аларның кечкенәдән инсафлы, әдәпле булып үсүләренә ирешү - төп бурычларның берсе.

***Программаның максаты:***

- оешма эшенә барлык укучыларны да катнаштыру
- оешманың күмәк эшләре аша балаларның әйләнә-тирәне танып белүләренә һәм анда үзләренең урыннарын табуга ирешү
- оешма эшен уеннар оештыруда, планлаштыруда мөмкин кадәр күбрәк укучыларны тарту,  балаларның практик осталыкларын арттыру
- балаларның иҗади һәм мөстәкыйл эшләргә өйрәтү
- дөрес ял итәргә, буш вакытларын файдалы үткәрергә ярдәм итү
- уен эшчәнлеге аша балаларның яхшы сыйфатларын , сәләтләрен ачыклау
- үзләренең һәм иптәшләренең уңышларын дөрес бәяләргә, бер-берсенә ярдәм итәргә өйрәтү
- үз исемеңнең кадерен белү, оешманың абруен саклау

***Безнең кагыйдәләр***

1. Туган илеңнең, үз оешмаңның, узеңнең исемеңә тугрылыклы булу.
2. Үз халкыңның мирасын, гореф - гадәтләрен, тарихын, йола - бәйрәмнәрен белү.
3. Матурлыкны күрә белү.
4. Туган як табигатен саклау.
5. Уз сәламәтлегең турында кайгырту.
6. Яхшылардан үрнәк алу.
7. Ышанычлы иптәш булу.
8. Биргән сузеңдә тору.
9. Хезмәтеңне ярату.
10. Үзеңнән кечкенәләргә шәфкатьле булу, олыларны хөрмәт итү, ялгыз әби-бабайларга ярдәм итү.

# ***ПЛАН***

## ***“Гүзәллек юнәлеше”***

| *№ п/п* | *Эш төре* | *Үтәлү вакыты* | *Җаваплы кеше* |
|---|---|---|---|
| *1* | *Белем бәйрәме. “Исәнме, мәктәп!”* | *1 Сентябрь* | *1,9 классларның кл. җит, педагог-оеш, тәрбия завучы* |
| *2* | *Татарстан Варислар Берлегенең туган көне* | *15 Сентябрь* | *Педагог-оеш, класс активы* |
| *3* | *“Сез иң гүзәл кеше икәнсез”* | *Октябрь* | *Отряд берлеге* |
| *4* | *Өлкәннәр көне* | *Октябрь* | *Кл. җит, пед-оештыручы,* |
| *5* | *Көз бәйрәмнәре. Шаян көз. (1-9 кл) “Көзге муллык* | *Октябрь* | *Кл. активы, пед-оеш., кл җит.* |
| *6* | *Мәктәптә театр атналыгы* | *Ноябрь* | *Кл. активы, пед-оеш., кл җит.* |
| *7* | *Яңа ел кичәләре.“Кыш бабайда кунакта” (1-9 кл)* | *Декабрь* | *Кл. активы, пед-оеш., кл җит.* |
| *8* | *Хакимият башлыгы елкасында катнашу.* | *Декабрь* | *Пед-оеш* |
| *9* | *“Кыш бабай остаханәсе” кар сыннары ясау, конкурс оештыру.* | *Декабрь* | *Кл. активы, пед-оеш., кл җит.* |
| *10* | *Класс почмакларына конкурс* | *Октябрь-ноябрь* | *Кл. активы, пед-оеш., кл җит.* |
| *11* | *“Ягез әле, егетләр” (23 Февраль гә бәйрәм)* | *Февраль* | *Кл. активы, пед-оеш., кл җит.* |
| *12* | *8 март бәйрәменә багышланган кичә. ”Кызлар-йолдызлар”* | *Март* | *Пед-оеш., кл җит* |
| *13* | *“Алтын каләм” түгәрәгендә катнашу. Без Тукай оныклары* | *Апрель* | *Фән укыт.* |

## ***“ВАРИСЛАРДА КУНАКТА”***

| ***№ п/п*** | ***Эш төре*** | ***Үтәлү вакыты*** | ***Җаваплы кеше*** |
|---|---|---|---|
| *1* | *“Туган көнең белән Варисым!”* | *Сентябрь* | *дружина берл* |
| *2* | *Дружина берлеге утырышы* | *Айга бер тапкыр* | *дружина берл* |
| *3* | *Дружина сборлары* | *Ноябрь, апрель, май* | *дружина берл* |
| *4* | *Отряд сборлары* | *Айга бер тапкыр* | *Вожатый, ДСП* |
| *5* | *Дружина почмагын җиһазлау, тулыландырып тору* | *даими* | *Дружина берлеге.* |
| *6* | *Отряд почмакларын яңарту, яңаларын булдыру.* | *Сентябрь, октябрь* | *Отрядларда.* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | *Республика, район буенча игълан ителгән акцияләрдә актив катнашу.* | *Билгеләнгән график буенча* | *Пед-оеш, друж. берл, кл. җит.* |

## *“БЕЛЕМ ЮНӘЛЕШЕ”*

| **№ п/п** | ***Эш төре*** | ***Үтәлү вакыты*** | ***Җаваплы кеше*** |
|---|---|---|---|
| 1 | *Һәр класста уку буенча җаваплы укучылар билгеләү* | *Сентябрь* | *Дружина берлеге,кл. Активы, кл. Җитәкчеләре* |
| 2 | *Авыр үзләштерүче балаларга шефлар* | *Сентябрь* | *Кл. активы* |
| 3 | *“Сумкада ниләр бар?” –классларда рейдлар үткәрү* | *даими* | *Дружина берлеге* |
| 4 | *Дәреслекләр тотышын тикшерү рейдлары* | *Октябрь-май* | *Дружина берлеге* |
| 5 | *Фән атналыклары* | *График буенча* | *Фән укытучылары* |
| 6 | *“Иң чиста көндәлек” конкурсы* | *Февраль* | *Пед-оеш, дружина берлеге* |
| 7 | *Әлифба бәйрәме* | *Апрель* | *Башл. Кл. укытучылары, группа вож.* |

## *“ШӘФКАТЬЛЕЛЕК ЮНӘЛЕШЕ”*

| **№ п/п** | ***Эш төре*** | ***Үтәлү вакыты*** | ***Җаваплы кеше*** |
|---|---|---|---|
| 1 | *Карлыгач группаларына вожатыйлар билгеләү* | *Сентябрь* | *Пед-оеш* |
| 2 | *“ШӘФКАТЬЛЕЛЕК” операциясендә катнашу* | *Ел дәвамында* | *отрядлар* |
| 3 | *Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәлне чистартып, карап тору.* | *Ел дәвамында* | *отряды* |
| 4 | *Сулыкларны, чишмәләрне чүпләрдән арындыру* | *Ел дәвамында* | *“Елмаю”отряды* |
| 5 | *Кышын,язын, көзен йөри торган таулы юлларны карап тору* | *Ел дәвамында* | *отрядлар* |
| 6 | *Инвалид балаларга яңа ел бүләге әзерләү* | *декабрь* | *Мәктәпкүләм* |
| 7 | *Тимурчылык эше* | *Ел дәвамында* | *Отряд берлекләре* |

## *“ХЕЗМӘТ ЮНӘЛЕШЕ”*

| № п/п | Эш төре | Үтәлү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Мәктәп яны тәҗрибә участогында эшләү | Октябрь, май, июнь | Кл. җит. |
| 2 | Дружинада хезмәт юнәлеше буенча җаваплы кешеләр белән эш. | Ел дәвамында | отряд берлеге |
| 3 | Макулатура җыю | Билгеләнгән вакытта | отряд берлеге |
| 4 | Тимурчылык эшенең торышын даими тикшерү | Ел дәвамында | Пед-оеш. |
| 5 | Мәктәптәге тәртип, чисталык өстендә эш. Дежурлык, генераль уборкаларны контрольдә тоту. | Ел дәвамында | Дежур класс, отряд берлеге |
| 6 | Укуга яхшы караш булдыру | Ел дәвамында | Пед-оеш |

## “СПОРТ, СӘЛАМӘТЛЕК ЮНӘЛЕШЕ”

| № п/п | Эш төре | Үтәлү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Көзге урманга, болынга сәяхәт | Сентябрь | Кл. җит.1 |
| 2 | “Көзге кросс” спорт ярышы | октябрь | Зайнуллин Х.Х., кл. җит |
| 3 | Шашка, шахмат уеннары оештыру | Ноябрь | Дежур укытучылар |
| 4 | Хоккей мәйданчыгы урнаштыру, уеннар башлау. | Декабрь | Зайнуллин Х.Х. |
| 5 | Чаңгы, чаналар белән кышкы табигатькә экскурсияләр | Декабрь-январь | Кл җит. |
| 6 | Мәктәп беренчелегенә чаңгы ярышлары | Февраль | Зайнуллин Х.Х. |
| 7 | Сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру буенча әңгәмәләр. | Даими | Кл. җит. |
| 8 | Волейбол, баскетбол уеннары. | Даими | Пед-оеш |
| 9 | Футбол уеннары. | Апрель-май | Кл. активы, пед-оеш., кл җит. |
| 10 | Республика, район буенча игълан ителгән ярышларда катнашу. | Декабрь | Кл. активы, пед-оеш., кл җит. |

## “ХОКУК ЮНӘЛЕШЕ”

| № п/п | Эш төре | Үтәлү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Юл хәрәкәте иминлеге, пожар куркынычсызлыгы, шәхси куркынычсызлык кагыйдәләре буенча әңгәмәләр | даими | Кл. җит |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | *Бала хокуклары конвенциясе кабул ителү көнен билгеләп китү. (әңгәмә)* | *20-ноябрь* | *Кл. җит* |
| 3 | *РФ Конституциясен кабул иткән көн. Классларда әңгәмәләр* | *12- Декабрь* | *Кл. җит* |
| 4 | *Район буенча игълан ителгән төрле конкурсларда катнашу* | *январь* | *пед-оеш* |
| 5 | *Юл иминлеге буенча үткәрелгән район конкурсында катнашу (“ИМИН ТӘГӘРМӘЧ”)* | *Сентябрь, апрель- май* | *Пед-оеш.,* |

## *ХӘРБИ-ПАТРИОТИК ЮНӘЛЕШ*

| *№ п/п* | *Эш төре* | *Үтәлү вакыты* | *Җаваплы кеше* |
|---|---|---|---|
| 1 | *“Туган ягым минем-Татарстан” Республика көне* | *Сентябрь* | *Кл. җит* |
| 2 | *“Шәфкатьле булыйк” шәфкатьлелек акциясенә старт* | *Ел дәвамында* | *Отряд берлеге* |
| 3 | *Өлкәннәр көне* | *1 Октябрь* | *Башлангыч кл* |
| 4 | *Сугыш ветераннарына Яңа ел бәйрәме белән котлау юллау.* | *Декабрь* | *Дружина берл* |
| 5 | *Мәктәп беренчелегенә чаңгы ярышлары* | *Декабрь-январь* | *Зайнуллин Х.Х.* |
| 6 | *23- Февраль Ватанны саклаучылар көне. “Аҗаган” уенын үткәрү* | *Февраль* | *Зайнуллин Х.Х.Отрядлар, пед-оеш,* |
| 7 | *Сугышчан интернационалистларны искә алу Очрашулар оештыру* | *15-февраль* | *Пед. оеш., отряд. Берл.* |
| 8 | *Һәйкәл янын чистарту* | *даими* | *отрядлар* |
| 9 | *.”Аларның даны мәңгелек” Ватан сугышында һәлак булганнарны искә алу. Венок салу. Тыл хезмәтчәннәре белән очрашу* | *май* | *Кл. активы, пед-оеш., кл җит.* |

## *Дружина берлеге алдына куелган максат һәм бурычлар:*

- ✓ *Укучылар эшчәнлегенең актив формаларын эзләү һәм күмәк-иҗади эшчәнлектә файдалану;*
- ✓ *Бер-береңә ихтирамлык, коллективизм тәрбияләү;*

- ✓ *Баланың кызыксынуын, сәләтләрен ачуда, яңа белемнәр һәм күнекмәләр туплау;*
- ✓ *Әйләнә-тирәгә кешелекле мөнәсәбәт тәрбияләү;*
- ✓ *Педагогик коллективта тәрбия эшенә бердәм караш булдыру;*

## *Дружинага бәяләмә*

“Дуслык” оешмасында барлыгы 67 бала исәпләнә. Дружинадагы отрядлар исемлеге: ”Карлыгач”, “Варис”, “СМС-дети”, “Волонтеры Победы”, “ЮИД” , “Юнармия”, “Доброе сердце”, “Форпост”, “Беркут”, “Орлята России”, “Движение Первых”.

***1 класс “Дуслык”*** – 7 укучы
Отряд командиры: Шигабиев А.
Девиз: Бердәмлектә көч.

***2 класс “Кояшкай”*** – 3 укучы
Отряд командиры: Абдуллин А.
Девиз:Кояшта күпме нурлар,
Шулкадәр безнең дуслар.

***3 класс “Дуслык”*** -9 укучы
Отряд командиры: Бәдретдинов К.
Девиз:Без төрле, әмма без бергә.

***4 класс “Тиенкәй”*** -6 укучы
Отряд командиры: Хаметшин К.
Девиз: Тиен кебек җитез бул,
Әдәпле бул, зирәк бул
Һәркайда да үрнәк бул.

***5 класс “Кояшкай”*** – 8 укучы
Отряд командиры: Хуснутдинов Ф .
Девиз:Кояшта күпме нурлар,
Шулкадәр безнең дуслар.

***6 класс “Ялкын”*** – 6 укучы
Отряд командиры: Муртазин Д.
Девиз:Укырга,тырышырга,эзләргә,табарга.

***7 класс “Йолдызчыклар”*** – 8 укучы
Отряд командиры:Хаметшин Р.
Девиз:Йолдызларда якты яныйк.

***8 класс «Звездная Бригантина»*** – 8 укучы

Отряд командиры :Хайруллин А.
Девиз:Наш класс – это просто Созвездие звезд!

***9 класс "Дуслык"*** -9 укучы
Отряд командиры: Мухаметзянов Ф.
Девиз:Без төрле, әмма без бергә.

## ***Дружина берлеге***

Дружина берлеге рәисе: Заляева Альмира
Ярдәмчесе: Миннебаева Диләрә
Байрак йөртүчесе:Муртазин Дияр
Быргычы: Валиахметов Нияз
Барабанчы: Сагатдинов Ильмир
Белем юнәлеше: Гильмутдинова Зәринә
Гүзәллек юнәлеше: Гильмутдинова Адилә
Шәфкатьлелек юнәлеше: Насыйрова Зәринә
Хезмәт юнәлеше: Закиров Зөлфәт
Спорт, сәламәтлек юнәлеше: Рахимов Рәзил
Хокук юнәлеше: Хайруллин Айдар
Хәрби-патриотик юнәлеше:Губаев Раяз

### ***Шефлык итәбез***

**" Ялкын"отряды**: ветераннарга котлаулар
**"Дуслык"отряды**: чишмә, сулыклар, йөри торган тауларны чистарту
**"Йолдызчыклар "отряды**: Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәл яннарын чистарту

### ***Безнең вожатыйлар***

1- 3 класс- Муртазина А., Миннебаева Д.
2 - 4 класс- Канафиева А., Насыйрова З.

## **Дружина утырышының перспектив планы**

2023-2024 уку елы

| № | Эш төре | вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Дружина советына яңа членнар җәлеп итү.Дружинаның перспектив планы белән танышу. Сентябрь аена эш планы төзү. | Сентябрь | Пед-оеш., ДСП |
| 2 | Укучылар сараеннан җибәрелгән акцияләр белән танышу. Өлкәннәр көненә әзерлекне карау.Көзге бәйрәмгә, укытучылар көненә әзерлекне | Октябрь | Пед-оеш., ДСП |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | барлау.Октябрь аена эш планы төзү. | | |
| 3 | Шәфкатьлелек операциясе. Кышлаучы кошларны каршыларга әзерлек.Юнәлеш җитәкчеләренең эш планы белән танышуы. Ноябрь аена эш планы төзү. | Ноябрь | Пед-оеш., ДСП |
| 4 | Яңа елга әзерлек. Декабрь аена эш планы төзү. Дружина советы членнарының ярты елга отчетлары. | Декабрь | Пед-оеш., ДСП |
| 5 | Акцияләрнең үтәлешен күзәтү.Январь аена эш планы төзү.Хезмәт юнәлеше эшенең торышы белән танышу. | Январь | Пед-оеш., ДСП |
| 6 | “Ватанны саклаучылар” көненә әзерлек эшләре алып бару. Февраль аена эш планы төзү.Отрядларның эшчәнлекләрен күзәтү.. | Февраль | Пед-оеш., ДСП |
| 7 | Март аена эш планы.8 март, “Нәүрүз” бәйрәмнәрен үткәрүгә әзерләнү.Отряд, группа вожатыйлары эшенең торышы. | Март | Пед-оеш., ДСП |
| 8 | Тукай көненә әзерлек.Шәфкатьлелек эшенең торышы белән танышу.Яшелләндерү операциясенә әзерлек. (бөре җыю).Апрель ае өчен эш планы. | Апрель | Пед-оеш., ДСП |
| 9 | 9 май бәйрәменә-Бөек Җиңүнең 79 еллыгына әзерлек.“Соңгы кыңгырау” бәйрәменә әзерлек.Еллык эшкә отчет-сайлау утырышы үткәрү. | май | Пед-оеш., ДСП |

## Сентябрь аена эш планы

| № | Эш төре | вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | “Исәнме мәктәп” белем бәйрәме | 1 Сентябрь | Оештыручы, кл. җит. |
| 2 | Дружина утырышында катнашу | Ай башы | Дружина членнары |
| 3 | Класста генераль уборкалар үткәрү. | Атнага бер тапкыр | Хезмәт юнәлеше |
| 5 | Мәктәп бакчасында эшләү. | Сентябрь | Хезмәт юнәлеше |
| 6 | Мәктәптә тәртип, чисталык өстендә эш. | Даими | Класс активы |

## Октябрь аена эш планы

| № | Эш төре | вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Отрядларда актив сайлау | Октябрь | ОСП |
| 2 | Дружина утырышында катнашу | Ай башында | Дружина членнары |
| 3 | Класста генераль уборкалар үткәрү. | Атнага бер тапкыр | Хезмәт юнәлеше буенча җаваплы |
| 4 | Мәктәптә тәртип, чисталык өстендә эш. | даими | Хезмәт юнәлеше җит |
| 5 | Класс почмакларын эшләп, | 20.10 | ОСП |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | яңартып кую | | |
| 6 | “Көзге табын-бай табын” кичәсенә әзерлек. Тәртип, рейдлар үткәрү. | 26.10 | Кл. җит., пед-оешт. |
| 7 | Варислар стендын яңарту | Даими | Дружина берлеге |
| 8 | Дәресләргә системалы йөрү | даими | Кл.җит. |

# Ноябрь аена эш планы

| № | Эш төре | вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Дружина берлеге утырышы | Ай башы | ДСП,ОСП |
| 2 | Отрядларда сборлар | Айга бер тапкыр | ОСП |
| 3 | Мәктәптә Хәйрия айлыгы. -ярминкәләр<br><br>-тимурчылык эшләре<br><br>-нәниләргә ярдәм (вожатыйлар эшчәнлеге) | даими | Пед-оешт. |
| 4 | “Без талантлар эзлибез”. Мәктәпкүләм иҗат фестивалендә катнашу-җыр-бию-нәфис үз | Ноябрь | Класс активы |
| 5 | Классларда рейдлар үткәрү. | Һәр атнаның чәршәмбесе | Белем юнәлеше җитәкчеләре |
| 6 | Дружина сборы. “Карлыгач” балалар оешмасына кабул итү. | Ноябрь | Пед-оешт. |
| 7 | Республика буенча игълан ителгән акцияләр: Бөек Җиңүгә 79 - ел! | Ноябрь | Варисларда кунакта юнәлеше җит. |
| 8 | Мәктәптә тәртип, чисталык өстендә эш. | даими | Класс активы |

# Декабрь аена эш планы

| № | Эш төре | вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Отрядларда сборлар үткәрү | Декабрь | ОСП |
| 2 | Дружина утырышында катнашу | Ай башында | Дружина членнары |
| 3 | Мәктәптә тәртип, чисталык өстендә эш. | Даими | Хезмәт юнәлеше буенча җаваплы |
| 4 | Тимурчылык эшенең нәтиҗәләре. | Даими | Шәфкатьлелек юнәлеше җит. |
| 5 | Активлар укуы | Айга бер тапкыр | Пед-оешт |
| 6 | Фән атналыкларында актив катнашу. | График буенча | Фән укытучылары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | Яңа ел тамашаларына әзерлек. 1-9 класслар “Кыш бабайда кунакта” | декабрь | Кл. җит., пед-оешт. |
| 8 | “Безнекеләрне бел”- зур уенга әзерлек эшләре алып бару. | Билгеләнгән вакытта | Дружина берлеге |
| 9 | “Карлыгач” группаларында “Сәламәтлек мәйданчыгы” айлыгы | Ай дәвамында | Дружина берлеге, вожатыйлар |
| 10 | Бөек Җиңүнең 79 еллыгына багышланган конкурсларда катнашу Рәсем конкурсы, | Ай буе | “Белем юнәлеше” җит., “Гүзәллек юнәлеше” җит. |

# Январь аена эш планы

| № | Эш төре | вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Дружина берлеге утырышы | январь | ДСП |
| 2 | Отрядларда сборлар үткәрү | График буенча | ОСП |
| 3 | Активлар укучылары утырышы | Айга бер тапкыр | Пед-оешт. |
| 4 | Тимурчылык эше буенча җаваплы кешеләр белән утырыш | Айга бер тапкыр | Шәфкатьлелек юнәлеше җит |
| 5 | “Карлыгач” группаларында “Хыял һәм фантазия” айлыгы | Ай дәвамында | Группа вожатыйлары |
| 6 | Мәктәптә уку, тәртип, чисталык өстендә эш. | даими | “Белем юнәлеше” җит. |
| 7 | Бөек Җиңүнең 79 еллыгына багышланган конкурсларда катнашу | Ай буе | “Белем юнәлеше” җит., “Гүзәллек юнәлеше” җит. |

# Февраль аена эш планы

| № | Эш төре | вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Дружина берлеге утырышы | 2 Февраль | ДСП |
| 2 | Классларда генераль уборкалар үткәрү. | Атнага бер тапкыр | Класс активы |
| 3 | Хәрби –патриотик һәм спорт айлыгы<br>-“Ажаган” уенында катнашу.<br>-классларда бәйрәм чаралары<br>-егетләр өчен хоккей | Ай дәвамында<br>Билгеләнгән вакытта<br>20-23–Февраль | Дружина берлеге<br>Кл. җит.<br>Пед-оешт.<br>Кл. җит. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | мәйданчыгында уеннар.<br><br>-чаңгы ярышлары | График буенча<br><br>График буенча | Зайнуллин Х.Х. |
| 4 | Фән атналыкларында катнашу. | График буенча | Фән укытучылары |
| 5 | “Өч күзле король”патшалыгында айлыгы – “Карлыгач” балалар оешмасында. | 1-28 Февраль | Группа вожатыйлары |
| 6 | Активлар укуы | Айга бер тапкыр | Пед-оешт. |

# Март аена эш планы

| № | Эш төре | вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Дружина берлеге утырышы | Ай башы | Дружина члennары |
| 2 | Класста генераль уборкалар үткәрү. | Атнага бер тапкыр | Хезмәт юнәлеше буенча җаваплы |
| 3 | “Кояш гомере телим мин, әнием сиңа!”<br><br>Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан кичәләр:<br><br>- “Минем кадерле әнием!” – иншалар бәйгесе. 1-5 класслар арасында.<br><br>- “Әнием һөнәре” темасына рәсемнәр күргәзмәсе. 1-4 класслар арасында | Ай дәвамында<br><br>Айның беренче атнасы<br><br>6-10 март | Кл активлары<br><br>Кл.җит.<br><br>Отряд вожат |
| 4 | Классларда бәйрәм чаралары. | 5-8 март | Кл. җит., класс активы |
| 5 | “Ягез әле, кызлар!” бәйгесе. | 7 март | Пед-оешт. |
| 6 | Хәйрия елы уңаеннан шәфкатьлелек ярминкәсе | 15 март | Пед.оешт., шәфкатьлелек юнәлеше җит. |
| 7 | Отряд сборлары:<br><br>-5 кл –“Без табигать дуслары” темасына<br><br>-6кл – “Табигать һәм без” темасына<br><br>- 7 кл – “Мавыгулардан һөнәр | 16 март<br><br>19 март<br><br>21 март | ОСП,пед-оешт,<br><br>ОСП,пед-оешт,<br><br>ОСП,пед-оешт, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сайлауга “ темасына | | |
| 8 | Активлар укуы | Айга бер тапкыр | Пед.оешт. |

## Апрель аена эш планы

| № | Эш төре | вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Дружина берлеге утырышы | Ай башы | ДСП, пед.-оешт |
| 2 | Тимурчылык эшен дәвам итү, билгеләнгән ялгыз әбиләргә бару. | Атнага бер тапкыр | Хезмәт юнәлеше буенча җаваплы |
| 3 | Отрядларда отчет –сайлау сборлары | Билгеләнгән вакытта | ОСП, пед-оешт, кл. җит. |
| 4 | Бөре җыю | Апрель | Хезмәт юнәлеше буенча җаваплы |
| 5 | Һәйкәл янын чистарту | Апрель | “ ” отряды |
| 6 | Класста генераль уборкалар үткәрү. | Атнага бер тапкыр | Класс активы |
| 7 | Башлангыч классларда “Табигать кочагында” айлыгы игълан итү | Ай буена | Группа вожатыйлары |
| 8 | Район буенча үткәрелә торган “Имин тәгәрмәч” конкурсына әзерлек эшләрен башлау. | Ай ахыры | Пед-оешт. |
| 10 | 4,5,6,7-класс варислары катнашында дружина сборы “Мин варисың синең Татарстан!” | 28 - Апрель | ДСП, пед-оешт. |

## Май аена эш планы

| № | Эш төре | вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Дружина берлеге утырышы | Ай башы | ДСП, пед.оешт. |
| 2 | Тимурчылык эшен дәвам итү, билгеләнгән ялгыз әбиләргә бару | Атнага бер тапкыр | Хезмәт юнәлеше буенча җаваплы |
| 3 | Отрядларда отчет –сайлау сборына, традицион үткәрелә торган “Дуслык” учагына әзерлек эшләре алып бару | Билгеләнгән вакытта | ОСП, пед-оешт. |
| 4 | 9 май,Бөек Җиңүн 79 еллыгына багышланган митингта катнашу. | май | Администрация |
| 5 | Һәйкәл янын чистарту | Май | Отряд берлеге |
| 6 | Классларда генераль уборкаларны даими ясап тору | Атнага бер тапкыр | Класс активы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | Соңгы кыңгырау бәйрәмендә актив катнашу | 25 май | Администрация |

# Кәче төп гомуми белем  мәктәбенең
# “Дуслык” балалар оешмасының
# 2022-2023 уку елына еллык отчеты

Безнең балалар оешмасында 2022-2023 уку елында бик күп класстан тыш чаралар үткәрелеп килде. Ай башында утырышлар, төрле темаларга сборлар, мәктәп традицияләрен дәвам итеп бәйрәмнәр һәм сборлар оештырылды һәм күңелле итеп уздырылды. Әлеге үткәрелгән кичәләр укучыларның тормышын уку белән генә чикләмичә, мәктәп елларында укыган вакытларны истәлекле һәм файдалырак итеп үткәрергә булышлык итә.

Дружинадагы отрядлар исемлеге: ”Карлыгач”, “Варис”, ”РДШ”, “СМС-дети”, “Волонтеры Победы”, “ЮИД” , “Юнармия”

**Дружинаның үз алдына куелган максат һәм бурычлары бар:**

- Укучылар эшчәнлегенең актив формаларын эзләү һәм күмәк иҗади эшчәнлектә файдалану.
- Бер-береңә ихтирамлылык, коллективизм тэрбиялэү.
- Баланың кызыксынуын, сәләтләрен ачуда, яңа белемнәр һәм күнекмәләр туплау.
- Әйләнә-тирәгә кешелекле мөнәсәбәт тәрбияләү.
- Педагогик коллективта тәрбия эшенә бердәм караш булдыру.

Планлаштыру – мавыктыргыч эш. Ул коллектив пөхтә итеп язып отряд яки дружина почмагына элеп кую өчен генә түгел, ә үткән һәм булачак игелекле һәм файдалы эшләрне бергәләп анализлау өчен дә кирәк. Эшләгән эш кайчан кызыклы була сон? Билгеле, бала үзе теләп башкарса гына. Биредә ориентир булып безнең эшчәнлектә дүрт “үзебез” кагыйдәсе исәпкә алынырга тиеш:

-үзебез планлаштырабыз;
-үзебез оештырабыз;
-үзебез үткәрәбез;
-үзебез йомгак ясыйбыз.

Бу очракта һәркемгә эш табыла. Ел башында мәктәпнең класстан тыш чаралар үткәрү планына нигезләнеп дружинаның еллык эш планы төзелде. Варис эшләрен башлаганда дөрес юнәлеш алу өчен берлек эшенең 8 юнәлеше: Варисларда кунакта, Белем, Гүзәллек, Шәфкатьлелек, Хезмәт, Спорт һәм сәламәтлек, Хокук, Хәрби-патриотик юнәлешләре буенча эш планы төзелде, Бу юнәлешләр безгә эшне дөрес оештырырга ярдәм итә. Һәр юнәлешнең үзенең җаваплы кешесе билгеләп куелды. Алар бу юнәлешләр буенча кыскача нәтиҗәләрен үзләренең эш дәфтәрләренә язып баралар.

Карлыгач  балалар оешмасында Карлыгачның “Туган як буйлап сәхәтенә” старт бирелде.

Сентябрьнең беренче иртәсе. Белем көне. Барыбыз өчен дә бәйрәм көн. Балалар катнашындагы матур, үзенчәлекле, шигырь, җырга бай булган тантана белән үтте. Икенче өлеше классларда Республикабыз көненә багышланган ачык дәресләр белән дәвам итте.

3 - октябрьдә "Өлкәннәр көне" уңаеннан мәктәбебездә "Буыннардан килер безгә кирәк җылы" дип исемләнгән очрашу булды. Мәктәбебездә эшләп лаеклы ялга чыккан ветеран укытучыларыбыз, техник хезмәткәрләребез бу көнне безнең кунакларыбыз булдылар. Укучылар һәм ветераннарыбыз катнашында кечкенә генә бәйге-дәрес оештырылды. "Остазлар белән очрашу", икенче өлеше чәй өстәле артында дәвам итте.

Быелгы көз бәйрәме балалар күңелендә истә калырлык итеп үткәрелде. "Көз айларына сәяхәт" дип исемләнгән бу бәйрәмебез, чын мәгънәсендә исеменә карап җисеменә туры килеп тора иде. Һәр класс спортзалда көз айларына сүяхәт кылып төрле бәйгеләрдә, уеннарда катнашып күңел ачтылар, биеделәр, җырладылар. Өй эше итеп бирелгән "Супер яшелчәләр" гә конкурс оештырылды. Бу бәйрәмне оештыруда укчыларның, класс җитәкчеләренең фантазияләре бай булулары күренеп тора иде. Һәр класстан өч кыз көз айлары булып киенгәннәр иде. Шулар арасыннан мәктәпнең "Көз сылуын" сайлау булды. Алар төрле бәйгеләрдә катнашып, биеп, җырлап үз осталыкларын күрсәттеләр. Ә башка балалар төрле яшелчәләр булып киенеп шигырьләр сөйләделәр, җырладылар, биеделәр, төрле кызыклы уеннар уйнадылар.

Дружинаның карлыгач группалары катнашында сбор үткәрелде. 2 класс укучылары "Карлыгач" балалар оешмасына кабул ителделәр,күкрәкләренә кояшка, яктылыкка омтылучы, ирекле, язның беренче кошчыгы карлыгач төшерелгән значоклар тагылды.

Мәктәбебездә ноябрь "Мәрхәмәтлелек һәм шәфкатьлелек" ае итеп билгеләнде. Бу айда без бик күп файдалы эшләр башкардык. Отрядлардагы тимурчылык эшенә тукталып китәсе килә. Һәр отрядның билгеләп куелган ялгыз, ярдәмгә мохтаҗ әби-бабайларына даими ярдәм итеп тордык һәм әле дә үзебезнең ярдәмебездән ташламыйбыз. "Ялкын", "Дуслык", "Йолдызчыклар" отрядларын әйтеп китәбез. Аларга рәхмәт, бу изге эшләре югалып калмас, алдагы елларда да ярдәмләшеп торырлар дип ышанып калабыз. "Шәфкатьле булыйк" акциясендә бик актив катнашып, ноябрьдә үткән ата-аналар университеты көнне мәктәбебездә укучылар тарафыннан шәфкатьлелек ярминкәсе үткәрелде. Пешергән, консервланган,тегелгән, бәйләнгән әйберләрен сатуга куеп, җыелган акчаларын Бу акциядә эти-әниләр дә, укытучылар да читтә калмады. "Без талантлар эзлибез" мәктәп күләм иҗат фестивале, укучылар арасында булган талантларны эзләү, аларны башкаларга күрсәтү максатынннан чыгып үткәрелде. Бу фестиваль чын мәгънәсендә зур эш булды. Ноябрьдә әниләр көнендә алар уңышлы чыгыш ясадылар.Карлыгачлар ел буенча үзләренең "Туган як" буйлап сәяхәтләрендә катнаштылар, бу сәяхәт айлыкларга буленеп башкарылды. Сентябрь ае-"Хезмәткә-хөрмәт", октябрь ае-"Минем өй", ноябрь ае-"Әдәплеләр шәһәре",декабрь ае-"Сәламәтлек мәйданчыгы", январь ае-"Хыял һәм фантазия", февраль ае-"Өч күзле король патшалыгында", март ае-"Матурлыкта кунакта",

апрель ае- “Табигать кочагында”, май ае-“Каникуллар ярымутравы”. Бу айлыкларда карлыгачлар төрле кичәләрдә, бәйрәмнәрдә катнаштылар, конкурслар, викториналар, уеннар үткәрделәр, төрле файдалы темаларга әңгәмәләр тыңладылар.Мәктәпнең традицион бәйрәмнәре Яңа ел, Ватанны саклаучылар көне, 8 март бәйрәмнәре оешкан төстә, күңелле, матур үткәрелде.4 класстагы 5 укучыны Варислар берлегенә кабул итеп, муеннарына галстуклар бәйләдек. Алар әти-әниләре, укытучылар, варислар каршысында тантаналы антлар бирделәр. Ел саен район буенча үткәрелгән “Имин тәгәрмәч” конкурсында катнашып киләбез. Һәр ел саен эшебезгә йомгак ясап Сабантуй мәйдәнында “Дуслык учагы” үткәреп киләбез. Быел без 1-9 класс укучылары катнашында балалар Сабантуе үткәрдек. Йоласына туры китереп төрле ярышлар, бәйгеләр үткәреп, баларның күңелләрен күтәрергә тырыштык, бүләкләр дә булгач бәйрәм чын мәгънәсендә Сабантуй булды. Соңыннан тәмле итеп алып килгән тәмле-тәмле ризыклар белән сыйландылар. Бәйрәмне матур итеп оештырып, үткәреп, урыннарны чүпләрдән арындырып өйләргә таралыштык. Шулардан чыгып йомгаклап, эшләнгән эшебезгә нәтиҗә ясап китәсем килә. Дружина алга куелган максатларга иреште. Алдагы елларда отрядларда сборны даими үткәрүне, тәртипкә, укучыларның бирелгән вазифаларына җаваплы карауларын ирешергә, укуга яхшы караш тәрбияләү юлларын эзләргә кирәк. Коллектив өчен мөһим булган кызыклы эшләрне тагын да күбрәк оештырырга.